КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 22 сентябрь г.Казань № 901

2030 елга кадәр Татарстан Республикасы
юлларында тормыш эшчәнлеге иминлеген
тәэмин итү концепциясен раслау турында

Татарстан Республикасы юлларында тормыш эшчәнлеге иминлеген арттыруның стратегик юнәлешләрен билгеләү, юл-транспорт һәлакәтләрен киметү һәм алар салган зыяннарның авырлыгын киметү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2030 елга кадәр Татарстан Республикасы юлларында тормыш эшчәнлеге иминлеген тәэмин итү концепциясен расларга.
2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга кадәр Татарстан Республикасында тормыш эшчәнлеге иминлеген тәэмин итү концепциясен раслау турында» 2011 ел, 30 май, 439 нчы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Административ һәм хокук саклау органнары идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин